Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы Кибәк Иле авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

Халык җыенын ике этапта үткәрү:

- Халык җыенының беренче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 28 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында узачак. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшел, Нариманов, Яңа, Бакча урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- Халык җыенының икенче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 28 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты янында узачак. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Чишмәле, Тукай, Мәктәп урамнары буенча теркәлгән кешеләрне дә кертергә кирәк;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем, 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- зират территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып

чыгарырга һәм Кибәк Иле авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сәйфетдинов